**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Бузай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

**2023 елның 23 ноябре** **№ 10**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең Бузай торак пунктында гражданнар җыены **карар кабул итте:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Бузай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән I төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) юлга вак таш салу;

2) юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү;

3) урамнарны яктырту челтәрләрен карап тоту;

4) урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру;

5) смета документациясен әзерләү һәм төзелеш контролен гамәлгә ашыру.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорт (СДК бинасы) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Зеленодольск муниципаль районы
Өтәшкә авыл җирлеге башлыгы. А.А. Клопов